**Нурмөхәммәтова Р.С., КФУ**

# «Чәй» лексемасының лингвомәдәни портреты

Аннотация. Данная статья посвящается описанию лексемы «чай», которая представляет один из ключевых концептов татарской лингвокультуры и в ней отражаются особенности национального менталитета. Понятие «чай» занимает видное место в языковой картине мира татар, обусловленное его особой ролью в питании татарского народа.

Ключевые слова: значение, лингвокультурология, лексема, чай, татарский народ.

Бу тикшеренүнең үзәгенә алынган «чәй» лексемасы татар лингвмәдәниятендә төп концептларның берсен тәшкил итә, анда татар халкының менталитеты ачык чагылыш таба. «Чәй» төшенчәсе татар тел дөнья сурәтендә үзәктә тора, бу аның татар халкы ашау культурасындагы роленә бәйле. Соңгы елларда тышкы факторлар тәэсирендә татарларның ашау-эчү системасында шактый үзгәрешләр күзәтелүгә карамастан, әлеге эчемлекнең иҗтимагый һәм мәдәни әһәмияте кимеми.

Тарихи мәгълүматлар буенча, чәй эчү традициясе татарларга Кытайдан кергән. Чәйне татарлар кайнар килеш, каты итеп, сөт, сөт өсте салып, бал белән эчәргә ярата. Бу эчемлекне еш эчү кырыс табигать шартларына каршы тору өчен дә зарур булгандыр. Татар халкы *кара чәй*гә өстенлек бирә. XX гасырның беренче яртысына кадәр *такта чәй* дә затлы саналган, чөнки *һинд чәе, сәйлүн чәйләре* гади халыкка барып җитмәгән. «Ачык чырай – такта чәй» әйтеменең бүгенге көнгә кадәр популяр булуы әлеге төр эчемлекнең киң таралган булуына ишарә итә. *Берничә сарык һәм ике йөк утын эшли алмаган эшне ике* ***такта чәй*** *әйләндереп чыгарды* (М.Мәһдиев «Кеше китә – җыры кала»). *Төрле тәм-томнар арасында күзне кызыктырган* ***цейлон чәе****нең бер кулга икешәр генә кап бирелүен белеп алгач мин, бөтен сәләтемне эшкә җигеп, сатучы ханымны авызыма караттым* (М.Галиев «Догалы еллар»).

Аңлатмалы сүзлеккә теркәлгән материал бу сүзнең күпмәгънәле булуына ишарә итә. Туры һәм күчерелмә мәгънәләр метонимия нәтиҗәсендә барлыкка килгән: 1) мәңге яшел көньяк агачы (куагы); 2) киптереп, махсус эшкәртелеп, капларга, төргәкләргә тутырылган чәй яфраклары; 3) шундый чәйне суга төнәтеп (пешереп) ясаган эчемлек; 4) чәй үсемлеге урынына төрле үлән, җиләк-

җимеш яфраклары яки җиләк-җимешне суга пешереп ясалган эчемлек [ТТАС 2005, 667].

Морфологик яктан караганда, «чәй» – матдә исемнәренә керә, ә андый исемнәр татар телендә ешрак берлек сан формасында кулланыла. Күплек сан кушымчасы белән кулланылганда ул чәйнең төрле сорты яки төре мәгънәсен аңлата.

«Чәй» сүзе *кайнар, салкын, куе, каты, сыек, яшел, кара, яңа, иске, бөртекле, сөтле, лимонлы, хуш исле* һ.б. сыйфатлар белән йөри. *Әби: «Локма да кабасым килми, **кайнар чәй** генә эчәр идем», – диде* (Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»). *Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән **куе чәй** китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде* (Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»). *Егет урман нигъмәтләре салып, **хуш исле чәй** пешерде* (К.Тимбикова «Тын бакчада»). *Нәркис, чәкәштереп, **каты чәй** эчте* (М.Мәһдиев «Фронтовиклар»). *Дамир стаканга балкашыгын шыкы-шыкы бәреп **салкын чәе**н болгатты* (Н.Гыйматдинова «Аргы очта, бирге очта»).

*Иртәнге, көндезге, кичке* сыйфатлары белән килгәндә ул билгеле бер аш вакытын да белдерә: ***Иртәнге чәй**не эчеп алалар да көне буе урамда, бакчада, кибетләрдә йөриләр икән тегеләр* (Д.Бүләков «Ачык ишек»). ***Көндезге чәй** кичке аш белән тоташты* (М.Мәһдиев «Фронтовиклар»). *Вәсим тиздән, җып-җылы өендә **кичке чәй** табыны тезеп куеп, каршына ике кызны утыртып сыйлаячагын күз алдына китереп балкып утыра* (К.Тимбикова «Тын бакчада»).

Гадәттә татарларда табынга чәй үзе генә бирелми, аның янына күп төрле чәй ризыклары да куела һәм бу тулаем бер ашауны алыштыра. *Коры чәй* оксюмороны ашамыйча гына чәй эчүне аңлата. Бу гыйбарә мохтаҗлык, ачлык заманнарында туган булырга тиеш.

Антоним буларак *чәй – су* парын күрсәтергә була. Бу очракта чәй – туклыклырак эчемлек кебек аңлашыла. Прагматик антонимы – *мәй* (фарсы теленнән кергән сүз: аракы, исерткеч эчемлек мәгънәсендә), *чәй – мәй* пары әлеге эчемлекне исерткеч эчемлеккә каршы куя: *Кирәксә – **чәй**, кирәксә – **мәй**, ипи, йомырка, бәрәңге, май...* (К.Кәримов «Сакау күке»).

Бу берәмлек мәкальләрдә дә бик күп очрый: *Кайнаган **чәй** эчелгәнгә исәп, бирелгән кыз киткәнгә исәп* (9865); ***Чәй**сез торып була, икмәксез торып булмый* (15428); *Әйрән эчкән ярлы бар, **чәй** эчкәннән ким түгел* (15490); *Ач карынга каты **чәй*** **(**15756); *Бар янында бар яхшы, **чәй** янында бал яхшы* (15758); *Бер чынаяк **чәй**нең кырык ел хәтере бар* (15759); *Кырда кайнаган **чәй** тәмле була* (15765); *Татар колагы катканчы **чәй** эчә, ди* (15773); ***Чәе** булса, шикәре табылыр* (15776); ***Чәй** көлдерер, кесәне бөлдерер* (15784); ***Чәй** яны – гаилә җаны* (15801); *Гыйлем **чәй** түгел, авызыңа тиз генә чөмерә алмассың* (30002) һ.б.

«Чәй» лексемасының фразеологизмнар составында кулланылышын күзәтү дә кызыклы: *ак койрыклы **чәй*** – бөртекле һинд чәенең арада ак кыл төсле койрыклы бөртекләре булганы; *арсак **чәй** эчәрбез* – «Армый эшлә! » дип сәламләгәнгә каршы уңайлы әзер җавап; *аулак **чәе*** – мәшәкатьтән һәм кешеләрдән арынып-бушанып, бер-ике кеше үзләре генә ял итеп, серләшеп, чәй эчеп утырулары; *аш артыннан – **чәй** шартыннан* – аш артыннан чәй эчерү татар табын йоласы; *ашың-**чәе**ң тәмле булсын* – табын өстенә туры килгәндә, ашаучыларга теләк итеп әйтем; *тезне тезгә куеп **чәй** эчү* – бик якын, бик үз булып, яратышып, чөкердәшеп, тату гаилә булып яшәү; ***чәй**не куян каны кебек ясау* – чәйне бик куе ясап эчү; *шыр **чәй*** – элек Кытайдан килә торган, камыш әрҗәгә тутырылган чәй; ***чәе**ннән Арча кыры күренә / **чәе**ннән кала күренә / **чәе**ннән Мәскәү юлы күренә* – чәе бик сыек, үтәли күренә димәктән һ.б

Шул рәвешчә, «чәй» лексемасын комлекслы итеп тикшерү барышында алынган материал нигезендә татар халкы кунакчыллыгының символы булган элеге эчемлек атамасының семантик, стилистик һәм функциональ мөмкинлекләре турында фикер йөртергә була.

**Чыганаклар**:

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.; II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 366 б.

Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – 2-нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.